| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.12.2021 ел Баулы шәһәре №235

2022 елда Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре укучыларын бушлай тукландыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» сәламәт туклану оештыру өлешендә СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү максатларында, шулай ук кайбер укучыларга өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2022 елда бушлай туклану белән тәэмин итәргә:

- шәһәр һәм район мәктәпләрендә бер үк вакытта белем алучы 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаиләләрдән балаларны;

- “Баулы муниципаль районында “Гаилә” балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют” ДКУ тәрбия алучы гомуми белем бирү мәктәпләрендә белем алучы балаларны;

- шәһәр һәм район мәктәпләрендә белем алучы инвалид балаларны.

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2022 елда җирле бюджетны үтәү барышында түләүсез туклану тәэмин итү буенча ташламалар бирү чараларына чыгымнарны каплауга финанс чаралары эзләргә.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Д.З. Ганиевага әлеге карар белән билгеләнгән шәһәр һәм район гомуми белем бирү мәктәпләрендә бер үк вакытта укучы 4 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары бирү турында мәгълүматны «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (ЕГИССО) куллану юлы белән,

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2021 елның 16 августындагы 1342 номерлы карары һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә тәртиптә һәм күләмдә җибәрүне (урнаштыруны) тәэмин итәргә,

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров